**СОВЕТ УСАДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район с.Усады, ул.Советская, д.41

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УСАД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Ус ад авылы, Совет ур., 41

Тел./факс: +7(84365) 73-2-75, e-mail: Usad.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**28 октября 2020 г.** **№ 9**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, «Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлегенең норматив хокукый актларын хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, Биектау муниципаль район Усад авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Үз көчләрен югалткан дип таныйрга:

Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Советының 2011 елның 15 апрелендәге 40а номерлы «Усад авыл җирлегенең Тышкы төзекләндерү, чисталыкны һәм тәртипне саклау кагыйдәләре нигезләмәсендә коррупциоген факторларны бетерү турында " карары»;

Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Советының 2016 елның 7 ноябрендәге 66 номерлы «Усад авыл җирлеге Советының «Усад авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, чисталыкны һәм санитар тәртипне тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында "26.05.2015 ел, № 316 карарына үзгәрешләр кертү хакында" турында карары»;

Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Советының 2014 елның 28 мартындагы 208 нче номерлы «Гражданнарның сәламәтлеген әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке тарту нәтиҗәләреннән саклау турында нигезләмәне раслау турында» карары;

Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Советының 2014 елның 28 мартындагы 211а нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Советының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советына тапшыру турында» карары;

Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Советының 2014 елның 28 мартындагы 210а нчы номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында» карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының

рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Ф.А.Забиров